КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 26 июль г.Казань № 655

Татарстан Республикасы халкына үзәкләштерелгән хәбәр итүнең төбәк автоматлаштырылган системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының һәм Россия Федерациясе Цифрлы нигездә үстерү, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгының «Халыкка хәбәр итү системалары турындагы нигезләмәне раслау турында» 2020 елның 31 июлендәге 578/365 номерлы боерыгы нигезендә, «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» 2020 елның 13 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы халкына үзәкләштерелгән хәбәр итүнең төбәк автоматлаштырылган системасы турындагы нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкына хәбәр итү системасы турындагы нигезләмәне раслау турында» 2017 ел, 28 август, 610дсп карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин